**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы, 38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 15 » марта 2019г. № 77

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
«Әтнә район мәдәният йорты»
муниципаль бюджет учрежденииесе
уставына өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Уставы нигезендә карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 19 мартындагы 104нче номерлы «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Әтнә район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе уставы турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Әтнә район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе уставына түбәндәге өстәмәләр кертергә:

1.1.Түбәндәге эчтәлекле 9нчы бүлекне өстәргә:

«9нчы бүлек. Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу».

Мәнфәгатьләр каршылыгы астында учреждение хезмәткәренең щәхси кызыксынуы аларның хезмәт вазыйфаларын тиешенчә башкаруына йогынты ясау мөмкинлеге, учреждение хезмәткәренең шәхси кызыксынуы һәм учреждениенең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре арасында каршылык барлыкка килергә мөмкин булган хәл аңлашыла.

Учреждение хезмәткәренең хезмәт вазыйфаларын тиешенчә башкаруына йогынты ясый яки йогынты ясый ала торган шәхси кызыксынуы дигәндә,

акча, кыйммәтләр, башка мөлкәт, шул исәптән милек хокуклары, яки үзе өчен яки өченче затлар өчен мөлкәти характердагы хезмәт күрсәтү рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге аңлашыла.

Учреждение җитәкчесе хезмәт вазыйфаларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә алучы шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында учредительгә (гамәлгә куючыга) хәбәр итәргә тиеш.

Учреждение хезмәткәре хезмәт вазыйфаларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә алучы шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында учреждение җитәкчесенә хәбәр итәргә тиеш. Учреждение җитәкчесенә хәбәр итү тәртибе, хәбәрдәге мәгълүматлар исемлеге, әлеге мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм хәбәрне теркәү тәртибе учреждение җитәкчесе тарафыннан билгеләнә.

2.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Әтнә район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе директорына Вәкаләтле органда оештыру документларында үзгәрешләр һәм өстәмәләр дәүләт теркәве буенча вәкаләтләр бирергә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әтнә муниципаль районы Советының оештыру бүлеге җитәкчесе Р. М. Галләмовага йөкләргә.

Әтнә муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Ф. Каюмов